Килешәм:
Байсар балалар бакчасы мөдире
_____________Г.М.Хаертдинова
“29” ____08______2023 ел

Раслыйм:
Байсар төп белем бирү мәктәбе директоры
___________________Р.З.Салахов
“29” _____08_______2023 ел

# Актаныш муниципаль районы
# муниципаль бюджет белем бирү оешмасы
# “Байсар төп гомуми белем бирү мәктәбе”
# структур бүлекчәсе “Байсар балалар бакчасы”
# 2023-2024 уку елына
# ЕЛЛЫК ЭШЧӘНЛЕК ПЛАНЫ

## Эчтәлек

**1.Эш структурасы турында белешмә**

1.1. Балалар бакчасы структурасы, материаль –техник база турында мәгълүмат
1.2.Балалар исемлеге
1.3. Педагогик кадрларга характеристика
1.4. Хезмәткәрләрнең эш графигы
1.5. Бакчаның еллык календарь уку графигы
1.6. 2023-2024 уку елына эш режимы.
1.7. 2023-2024 уку елына уку планы.
1.8. 2023-2024 уку елына белем бирү эшчәнлеге челтәре.
1.9. Узган уку елына анализ.
1.10 2023 -2024 уку елына бурычлар , эш программасы.

**2.Байсар балалар бакчасының еллык бурычларны тормышка ашыру планы.**

**I.Кадрлар белән эш.**
1.Педагогларның һөнәри квалификациясен күтәрү һәм социаль активлыгын үстерү.
2. Тәрбиячеләрнең методик темалары.
3.Район методик берләшмәсе утырышларында катнашу.

**II. Педагогик эшчәнлек.**
1.Педагогик киңәшмәләр
2.Семинар –практикумнар
3.Консультацияләр
4.Алдынгы эш тәҗрибәсен тарату

**III. Тәрбия һәм белем бирү эшенә контроль һәм җитәкчелек**
1 Оператив тикшерүләр
2 Тематик

**IV. Чаралар.**
1.Смотр –конкурслар.
2. Бәйрәмнәр –күңел ачулар
3.Атналыклар

**V. Методик кабинет эшчәнлеге**

**VI.Ата –аналар белән эш**
1. Ата-аналарны норматив документлар белән таныштыру.
2. Реклама блогы.
3. Консультацияләр
4. Ата-аналардан анкеталар алу:
5. Ата-аналар өчен төркемнәрдә информацияләр (ширма, стенд)
6. Ачык ишекләр көне
7. Ата-аналар белән бергә узган бәйрәм һәм чаралар
8. Уртак иҗат, күргәзмәләр
9. Гомуми җыелышлар.
10. Төркем җыелышлары

**VII. Административ хуҗалык эшләре.**

**3. Еллык планга кушымталар:**

1. Мәктәп белән элемтә планы
2. Күңел ачулар, чаралар һәм бәйрәмнәр планы.
3. Сәламәтләндерү һәм чыныктыру планы.
4. Юл-транспорт хәрәкәтендә куркынычсызлык планы.
5. Пожар куркынычсызлыгын тәэмин итү планы.

**Балалар бакчасының структурасы  һәм материаль –техник база турында мәгълүмат.**

Байсар балалар бакчасы  Актаныш муниципаль районы  Актаныш муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Байсар гомуми белем бирү мәктәбенең  структур бүлекчәсе булып  тора. Авыл  җирлегендәге, татар телендә эш алып баручы балалар бакчасы.  1992 нче   елның 1 нче сентябрендә  файдалануга   тапшырылды. 270 квадрат метр мәйданлы  типовой мәктәп белән бер бинага урнашкан бина.  Авыл уртасында урнашкан. Яхшы итеп яшелләндерелгән. Яшелчә бакчасы, уен мәйданчыгы бар.  Уен мәйданчыклары кече  архитектур   формалар   белән   җиһазланган. План нигезендә бакча 40 урынга исәпләнгән. 2023-2024 уку елында 2 төркемгә 17  бала  йөри. Бакча  9 сәгатьлек   эш режимында атнага 5 көнлек эш режимында эшли. Соңгы 3 елда бакчага йөрүче 5  яшьтән - 7 яшькәчә балалар йөреше   100 % булды.

Бакчада тәрбия-белем бирү эшчәнлеге түбәндәге норматив-хокукый документларга нигезләнеп оештырылды:

- РФ  Конституциясе (1993 г.).
- «Конвенция ООН о правах ребенка» (1989 г.).
- 29.12.2012 №273 – I  «Об образовании в РФ». РФ  Федераль  Законы
- Сан П и Н 2.4.1.3049-13 N 26 "Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций" РФ нең дәүләтенең баш  врачы карары белән 15 мая 2013 елда  расланган
 “ФГОС дошкольного образования” (  РФ мәгариф Министрлыгының 28.08.2013 г.).
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының методик тәкъдиме: мәктәпкәчә яшьтәге балаларга  татар (рус) телләрен өйрәтүне оештыру буенча 08.11.2013 елда чыккан  № 15588/13 белән теркәлгән.
- Татарстан  Республикасының «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республики Татарстан» законы. (в ред. Законов РТ от 28.07.2004 N 44-ЗРТ,от 03.12.2009 N 54-ЗРТ.0
- МБОУ “Байсар  төп гомуми белем бирү мәктәбе” уставы 2019 ел.
- МБОУ “Байсар төп гомуми белем бирү  мәктәбе” структур бүлекчәсе “Байсар балалар бакчасының” белем бирү программасы.
- Татарстан Республикасы мәгариф  һәм фән министрлыгының 2013 елның 20 январендә № 968/13  приказы белән   чыккан  “Об эффективности внедрении новых УМК”  хаты.
- РФ белем  бирү министрлыгының   1998 елның 2 нче июнендә № 89/34-16 приказы белән  чыккан «О реализации права дошкольных образовательных учреждений на выбор программ и педагогических технологий» хаты.

**Бакчага йөрүче балалар турында белешмә, аларның гаилә составы.**

2022-2023 уку елында Байсар балалар бакчасы 20 бала белән  комплектлаштырылды. Уку елы  дәвамында балалар йөреше  тотрыклы булды. 17  бала ата-аналар түләвенең  50 %  ташламасыннан файдаланды. 4 балага  -25 % , 8  балага  -50%, 8 балага -70 %   ата-аналар түләвеннән  компенсация каралды  һәм  бу компенсация  һәр балага да  вакытында кайтарылып барылды. 2022-2023  уку елында бакчага йөрүче балалар арасында авыр гаиләләр булмады.

| Уку елы | Гаиләләр турында информация | | | | | | | Яшәү шартлары | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бала саны | Гаилә саны | Тулы булм.г. | Күп балалы гаиләләр саны | Опекун | Социаль | | | | |
| | | | | | | Яхшы | Авыр | Яхшы | Кан. | Начар |
| **21-22** | 21 | 14 | 1 | 5 | - | 21 | 0 | 21 | 0 | 0 |
| **22-23** | 20 | 14 | 2 | 15 | - | 20 | 0 | 20 | 0 | 0 |
| **23-24** | 17 | 15 | 1 | 16 | - | 20 | 0 | 20 | 0 | 0 |

**Кадрлар белән тәэмин ителеш:**

Коллективта 1 югары белемле мөдир, 1 югары, 1 махсус урта белемле тәрбияче, 2 кече тәрбияче, махсус урта белемле 4 нче разрядлы 1 пешекче һәм 1 техник хезмәткәр хезмәт куйды.

| Уку елы | Категориясе | | | | Белеме | | | Стажы | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | югары | 1 кат. | Соот | катего-риясез | югары | махсус урта. | Урта | 5 елгача | 5-10 | 10-15 | 15-20 | 20 артык |
| **2022-2023** | - | 2<br>67 % | | -<br>% | 2<br>67% | 1<br>33% | -<br>% | -<br>% | -<br>% | -<br>% | 1<br>33% | 2<br>67% |
| | Барлыгы 3 педагог | | | | | | | | | | | |

**Бакчада белем һәм тәрбия бирүдә түбәндәге программалар кулланылды:**

- Байсар балалар бакчасының Н.Е. Вераксы, М.А.Васильева, Т.С.Комарова авторлыгында, ФДББС нигезләнеп бирелгән, 2014 елгы «От рождения до школы» программасын файдаланып төзелгән “Төп белем бирү программасы” (2015- елда алынган).
- Р.К.Шаехованың 2012 елда Казан шәһәрендә басылган «Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы».
- С.М.Гаффарова,Ч.М.Гаффарова, Г.З.Гарафиеваларның 2013 елда басылган «Изучаем русский язык» программасы.

**Балаларга белем һәм тәрбия бирүдә түбәндәге методик әсбаплар һәм:яңа укыту-методик комплектлары кулланылды:**

- Г.А.Галеева, С.М. Гаффарованың “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү циклы”;
- З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева,Р.С.Зөфәрованың «Туган телдә сөйләшәбез»;
- К.В.Закирова,Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллиналаның «Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе»;
- С.М. Гафарованың “Изучаем русский язык” һәрбер яшь төре өчен методик кулланмасы, рус теле өчен эш дәфтәрләре , деманстрацион таратма материаллар;
- К.В.Закирова,Л.Р.Мортазинаның «Балачак,уйнап-колеп үсәр чак»
- К.В.Закирова, Л.Р.Мортазинаның «Әй уйныйбыз,уйныйбыз»
- В.З.Латыйпованың “Балачак аланы”;

- З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова, А.Т.Миникаеваның “Непосредственно образовательная деятельность” ;
- З.М.Зарипова, Р.С.Исаеваның “Үстерешле уеннар”
- “И.Г.Вахрушеваның Путь к успеху”,Л.Ф.Блинованың «Я хочу», Г.Бардиерның “Психологическое сопровождение естественного развития”; И.Ромазанның «Игровая терапия с тревожными детьми» әсбәплары.
- Р.К. Шаехованың “Мәктәпкәчә яштәгеләр әлифбасы: Авазларны уйнатып 1-2 кис” эш дәфтәренә методик кулланма һәм эш дәфтәрләре -1.2 кисәк эш дәфтәрләре.
- З.М. Зарипованың “Татарча сөйләшәбез” методик кулланмасы һәм эш дәфтәрләре, театральләшкән уен ситуацияләре өчен деманстрацион таратма материаллар;
- “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” аудио кушымтасы;
- “Уйный –уйный усәбез” методик кулланмасына аудио-кушымта.
- «Шома - бас» аудио кушымтасы – 33 бию, мультипликацион фильмнар;
- «Минем өем» методик комплектына аудио кушымта. Һ.б.

**Белем –тәрбия эшчәнлеген алып бару өчен шартлар:**

Бакчабызда эшчәнлек өчен түбәндәге үсеш тирәлекләре киң файдаланылды: методик кабинет, мини-музей, яшь категорияләренә туры килгән уен бүлмәләре, балалар бакчасы тирәлеге – яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы, чәчәклекләр, спорт мәйданчыгы.

Бакчада балаларның төрле яклап үсеше өчен тудырылган шартлар ел дәвамында тулыландырылып торды. Предмет-үсеш тирәлеген балалар яшенә туры китереп, балаларның кызыксынуларын һәм таләпләрне искә алып җиһазланган. “Туган якны өйрәнәбез” –татар көнкүрешен чагылдырган кече музейда балалар татар халкының милли киемнәре, көнкүреш предметлары, йолалары, милли киемле курчаклар, шәҗәрәләр, элеккеге көнкүрештә кулланган җиһазлар белән таныша алалар. Шулай ук авыл тормышы, бакчада һәм мәктәптә эшләп лаеклы ялга чыккан педагоглар белән дә танышу мөмкинлеге тудырылган.

Методик кабинетка норматив документлар, методик, балалар өчен матур әдәбият һәм укыту методик комплектлары эшчәнлектә файдаланыла. Дидактик, күрсәтмә, таратма материаллары тышлап, эш дәфтәрләре, мультимедиа чаралары тиешле дәрәҗәдә кулланыла.

Рус теле почмагында балалар белән рус теле эшчәнлекләре уза, рус халык көнкүреше, бизәкләре, рус халык уеннары,уенчыклары, йолалары, бармак уеннары, бармак, кул театрлары, киемнәре белән танышу буенча даими эшчәнлек алып барыла.

Шулай ук бакчабызда бу уку елында да түбәндәге юнәлешләрдә эшчәнлек оештырылды:

-балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын планлаштырганда тәрбиячеләр белән оештырылган эшләр;

- бакчасында милли тәрбия бирү системасын планлаштыруда җәмәгатьчелек һәм мәктәп белән эш;

-милли-мәдәни тәрбия бирүдә ата-аналар белән эшчәнлек.

-милли-мәдәни тәрбия бирү өчен күрсәтмәлекләр.

**Белем бирү программасын тормышка ашыру шартлары һәм бурычлары:**

“Байсар балалар бакчасы”ның үсеш чорының 6 елын үз эченә алган “Төп белем бирү программасы”ның өч төп өлеше буенча да даими рәвештә эшчәнлекләр алып барылды.

**Программаның максатчан бүлеге буенча,** белем эчтәлеге спецификасын һәм белем-тәрбия процессын оештыруның үзенчәлекләрен характерлаучы норматив-хокукый документларга нигезләнеп алып барылды.

Байсар балалар бакчасының белем бирү программасы РФ Мәгариф һәм Фән Министрлыгының 30.08.2013 елда кабул ителгән №1014 “Об утверждении порядка

организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам” турындагы приказы; РФ Мәгариф һәм Фән Министрлыгының 17.10.2013 елда кабул ителгән №1155 «Об утверждении ФГОС дошкольного образования» приказы нигезендә һәм Н.Е. Вераксы, Т.С. Комарова, М.А. Васильеваның 2014 елда чыккан, «От рождения до школы» һәм Р.К.Шаехованың “ Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү” үрнәк программаларына нигезләнеп төзелгән.

Программаны үзләштерүдә уңышка ирешү чыганаклары булып тәрбиячеләрнең ФДББС түбәндәге 9 принцибын куллану торды:

1. Балачак этаплары (1,2-3 ранний, 3-8 дошкольный)
2. Мәктәпкәчә тәрбиядә индивидуальлелек –белем бирүэшчәнлеген һәр балага индивидуаль якын килү нигезендә төзелүе.
3. Өлкәннәр һәм балалрның теләктәшлеге – белем бирү эшчәнлегендә баланы тулы хокуклы катнашучы итеп тану.
4. Төрле төр эшчәнлекләрдә бала инициативасын хуплау.
5. Гаилә һәм бакча теләктәшлеге.
6. Балаларны- социаль мәдәни нормаларга тарту – гаилә,җәмгыять, дәүләт нормалары.
7. Төрле төр эшчәнлекләрдә балаларның танып белү кызыксынуларын һәм танып белү эшчәнлекләрен формалаштыру.
8. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь адекватлылыгы –(баланың яшенә һәм үсеш үзенчәлегенә шартларның, таләпләрнең туры килүе)
9. Бала үсешендә этник –мәдәни ситуацияләрне исәпкә алу.

Шулай ук укыту-тәрбия процессында укыту методик комплектларны куллану да балаларга төпле белем һәм тәрбия бирүдә ныклы ярдәмлек булып торды.

Белем бирү процессында 1,5-7 яшькәчә балалар, аларның ата-аналары һәм педагогик хезмәткәрләр катнаша. Төркемнәргә билгеләү Байсар төп гомуми белем бирү мәктәбенең Уставына нигезләнеп бүленде.

Бакчада балаларның төрле яклап үсеше өчен шартлар тудырылды. Материаль-техник база 2 төркемдә дә заман таләпләренә туры килә: кабул итү , уен, йокы, туалет бүлмәләре тиешле дәрәҗәдә кулланыла. Белем һәм тәрбия бирү процессын дәүдәт стандартларына яраклаштырып алып барыла, предмет-үсеш тирәлеген балалар яшенә туры китереп җиһазланган. Предмет-үсеш тирәлеге балаларның кызыксынуларын һәм таләпләрне искә алып төзелде. Элементлар бала үсешенә ярдәм итәрлек итеп яраклаштырылган. Ясле төркемендә уен зонасы өчен җиһазлар бар һәм ком-су зонасы, хәрәкәт, үстерешле белем бирү, экология, уен почмакларын балалар тәрбияче белән дә, мөстәкыйль дә шөгылләнерлек итеп үзгәртелгән. ФДББС нигезләнеп, уенның бала эшчәнлегендә төп рольне уйаганын һәм педагогларның күпчелек белем бирү бурычларын уен эшчәнлеге аша хәл итүләрен күз уңында тотып, 2022 – 2023 уку елында, икетеллелеккә өйрәтүне тормышка ашыруны дәвам итү максатыннан рус теле һәм ана теле почмакларын тулыландырдык. Төркемнәрдә тел мөхитын үстерү максатыннан рус һәм татар теле почмакларын ФДББС яраклаштырып тулыландырдык. Эшчәнлек өчен йокы, кабул итү бүлмәләре дә рациональ кулланыла. Анда балалар эшләренә күргәзмәләр, ата-аналар өчен мини- китапханәләр, эшчәнлектәге яңалыкларны чагылдырган ширмалар урнаштырыла.

Төркем бүлмәсендә балалар белән иртәнге гимнастика, физкультура, музыка, шөгылләре, күңел ачу, театр эшчәнлеге, бәйрәм иртәләре, ачык белем бирү чаралары һәм башка чаралар өчен кирәкле уен кораллары тулыландырылды, спорт инвентарьлары яңартылды. Балалар белән тулысынча эшләргә һәм мотор тыгызлыгын тиешле дәрәҗәдә үтәргә мөмкинлек тудырылган.

Балаларны юлда йөрү кагыйдәләренә еллык план нигезендә өйрәтүне алып барабыз. Шулай ук балалар белән ел дәвамында эшчәнлек алып бару өчен барлык шартларнны да

тудырдык. ПДД буенча ата-аналар эшләреннән конкурс- күргәзмәләр оештырдык. Балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча булган китаплар, методик ярдәмлекләр, дидактик материалларны тулыландырдык.
Хезмәтне саклау балаларның һәм хезмәткәрләрнең тормыш иминлеге саклау буенча таләпләр катгый куела. Янгын куркынычсызлыгына өйрәтү буенча практик шөгыльләр өчен ел дәвамында үткәрелә. Бакчаның бер өлешендә "2023 ел- Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы." уңаеннан стенд ясалып, чаралар планы төзелде һәм тормышка ашырылды. "Туган якны өйрәнү" темасына нигезләнеп ачылган кече музей тулыландырылды. "Педагог һәм остаз" елына багышлап бакчабызда эшләп, лаеклы ялга чыккан эшчеләр белән очрашулар оештырылды.
Бакча территориясендә предмет-үсеш тирәлеге балаларның тормышларын һәм сәламәтлекләрен күз уңында тотып оештырыла. Бу уку елы алдыннан һәр 2 төркемгә дә җәйге веранда, комлыклар, уен зоналары, кече спорт формаларын яңартып косметик ремонт ясалды.

**2022-2023 уку елында, бакча үсешендә түбәндәге бурычлар билгеләнгән иде:**

1. Программа таләпләрен үтәп, иҗади, системалы эшчәнлек аша, инновацион алымнар кулланып, цифрлаштыру буенча эшчәнлекне белем бирү программасына яраклаштырып тулыландыру аша танып белү эшчәнлегенең сыйфатын яхшырту, белем дәрәҗәсен камилләштерү.

2. Физик, акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерү, әхлакый - сәнгати зәвыклылык тәрбияләү юнәлешендә балаларда милли үзаң формалаштыру. Ике дәүләт теленә карата да хөрмәт тәрбияләү аша дәүләт телләренә өйрәтү сыйфатын күтәрү.

3. "ЭКО- балалар " проектына нигезләнеп балаларда табигатькә карата сак караш, матурлыкны күрә белүне үстерү аша балаларда миһербанлылык, кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү. Шундый сыйфатларга ия булган бала гына туган ягын ярата һәм аңа чын хуҗаларча карый беләчәк.

4. ФДББС таләпләрен тормышка ашыру шартларында педагогларның һөнәри осталыкларын һәм теоретик белемнәрен баету, квалификация дәрәҗәләрен күтәрү өстендә эшне дәвам итү. Хәзерге заман таләпләренә җавап бирерлек бердәм аралашу эшчәнлекләре уздыру.

5. Балалар тәрбияләүдә гаилә һәм балалар бакчасы арасындагы элемтәне камилләштерү. Тәрбиячеләр һәм ата-аналарның балалар каршындагы җаваплылыгын ассызыклап, балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү өчен оптималь шартлар тудыру.

Куелган бурычларнны коллектив, балалар, эти-әниләр һәм җәмәгатьчелек белән берлектә төрле ысуллар ярдәмендә гамәлгә ашырдык.
Балалар бакчасы эшенең төп юнәлеше «Заманча технологияләр куллану аша һәрьяклап үсеш алган көндәшлеккә сәләтле шәхес тәрбияләү». Бакча педагоглары бу эшне балаларны интеллектуаль яктан үстерү белән бәйләп алып баралар. Төрле яңа программалар, технологияләр балалар гыйлемен арттыруда ярдәм итә.
Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләп тәрбия һәм белем бирү процессын планлаштыруны билгеле бер темаларга берләштереп эшләдек. Мәсәлән : "Сәламәт тәндә – сәламәт акыл", "Тәрбияле бала – ил терәге", "Теле барның – иле бар", "Туган телем –иркә гөлем"," Уйный,уйный үсәбез", "Дуслык аланында (төрле милләтнең гореф гадәтләре)" һ.б. Бирелгән эчтәлекне үзләштерү өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә, шулай

ук балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә тормышка ашырылды. Һәр шөгыльне алып бару өчен перспектив планнар төзелде. Тәрбиячеләр календарь планнар төзеп, эшчәнлек эчтәлекләрен методик таләпләргә туры китереп төзеделәр.
Балалар бакчасында, тәрбия һәм белем бирү процессында тәрбиячеләр бик күп җырлы-биюле уеннар аша туган телгә мәхәббәт, кыюлык, тапкырлык, игътибарлылык тәрбияләделәр. Эшчәнлектә халык педагогикасын киң кулланып эшләделәр.
Узган уку елында мәктәпкәчә тәрбиядә педагогдарның төп компетенцияләренә ФДББС таләпләре булып балаларның эмоциональ уңышларын тәэмин итү; индивидуальлелек һәм балалар инициативасын хуплау; төрле очракларда үз-үзен тотышы һәм балалар белән үзара аралашу кагыйдәләрен булдыру; һәр тәрбияләнүче балага, якын тирәлектәге үсешенә ориентлашкан, үстерешле белем бирүне оештыру; якын тирәдектәге социум һәм бакчага йөрүче балаларның ата-аналары белән теләктәшлек булдыру торды. Педагогик кадрлар тарафыннан социаль- аралашу үсеше юнәлешендә бурычлар яхшылап үзләштерелеп, район күләмендә ачык чаралар игълан итттек.
Балалар белән әдәби әсәрләр аша тирәлектәге чынбарлыкны чагылдырган уен эшчәнлеген үстерү, матур әдәбияты, халык авыз иҗаты белән таныштру, мәкаль, әйтемнәрнең мәгънәсен аңлату, аларның сөйләмдәге урынын билгеләү максатлары алынды. Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән “Зәңгәр кул,яшел алан – без табигать дуслары” әкиятен сәхнәләштердек, Тукай әкиятләренә сәяхәт темасына төрле иҗади бәйгеләр, күргәзмәләр,очрашулар оештырылды. Мәктәп белән бәйләнешне ныгыту максатыннан башлангыч сыйныф укучыларына әкиятләр сәхнәләштерелде, инглиз телендә бердәм театрлаштыру эшчәнлеге, район күләмендә бәйгеләргә әзерлек алып барылды. Район күләмендә уздырылган инглиз телендә нәфис сүз, ялгыз һәм күмәк җыр бәйгеләрендә катнашып нәтиҗәле урыннарга ия булдык.
Бакча эшчәнлегендә балаларны социаль мәдәни нормаларга, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт традицияләренә тарту –төп бурычларның берсе булып кала.
Киләчәктә эш юнәлешен, кулланылачак ысулларны билгеләр өчен балалар бакчасы системалы рәвештә балаларның үсеш динамикасы күзәтелде. Балаларның танып белү дәрәҗәсен ачыклар өчен барлык төп юнәлешләр буенча диагностика үткәрелде. Мониторинг процессында федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән физик, социаль аралашу, танып белү, сөйләм, әдәби-эстетик үсешләр каралды.
Турыдан туры белем бирү эшчәнлеге: “Сөйләм үсеше”, “Социаль-аралашу үсеше” эшчәнлекләре буенча программа материалы яхшы дәрәҗәсендә үзләштерелде, балаларның сүзлек запаслары бай, ләкин сөйләмдә гомумиләштерүче сүзләр кулланып эшләү һәм җөмләне дөрес итеп төзү буенча кимчелекләр, авазларны дөрес әйтүдә кимчелекләр бар.
Белем бирүнең сыйфатын яхшырту өчен белем бирү процессында инновацион технологияләрне киңрәк куллану кирәк.
Яңа уку елында сөйләм үстерү мөхитен тулылыандыру, балалрның картинага карап хикәя төзүләренә, монологик сөйләмгә, авазларны дөрес итеп әйтү өчен махсус күнегүләргә басым ясарга кирәк дигән нәтиҗә ясалды.
- рус теленә өйрәтү буенча-сүзлек запаслары бай, порграмма таләпләренә туры килә, балаларның диалогик сөйләм торышы югары дәрәҗәдә, ләкин эле бәйләнешле сөйләм теле торышы буенча кыенлыклар бар. Алдагы уку елында ата-аналар белән даими эшләүне дәвам итәргә.
- танып-белү белем бирү өлкәсе –балаларның уйлау-фикерләү эшчәнлеге, иҗади һәм вариатив фикер йөртү, чагыштыру, гомумиләштерү, төркемләү, нәтиҗә ясау кебек психик процесслар үсеше күрсәткечләре яхшы дәрәҗәдә. Ләкин билгеле бер балалар белән индивидуаль эшкә басым ясарга кирәк.
Математик эчтәлекне үзләштерү процессында, төркемнәрдә белем бирү программасына яраклаштырылган эш дәфтәрләре белән тәэмин итү күз уңында тотыла.

Балалар бакчасы коллективы З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина, Ф.В.Хәзрәтованың “Математикага өйрәнәбез”, И.А.Помораева, В.А.Позинаның “Формирование элементарных математических представлений”старшая и подготовительная к школе группа, Г.Сафиуллина “Уйный ,уйный өйрәнәм” 2-3 яшь, И.А.Помораева, В.А.Позина “Занятия по формированию элементарных математических представлений” 2 младшая группа; методик әсбаплар кулланып эшли.

Бүгенге көндә балаларны үз ана телендә һәм рус телендә өйрәтү актуаль проблема булып кала. Милли тәрбия буенча Уставта каралган норматив документларга таянып эшлибез. Тәрбия һәм белем бирү татар телендә алып барылу сәбәпле, балаларга рус теле өйрәтелә. Бу проблеманы хәл итү өчен бакчада бар шартлар да тудырылган: татар теле һәм рус теле кабинетлары кирәкле җиһазлар һәм яңа комплектлар белән тулыландырылды (экран, мультимидия проекторы, аудио һәм видео-дисклар, русча, татарча мультфильмнар, ике телдә дә матур әдәбият, яшь үзенчәлекләренә карап УМК, әзер эшчәнлек конспектлары һәм эш дәфтәрләре), татар һәм рус халкының көнкүреш кирәк-яраклары, милли үзенчәлекләрен чагылдырган җиһазлар, кием-салымнар һ.б. тупланды. Татар халкының көнкүрешен чагылдырган кечкенә генә музей булдырылды. Балаларның татарча сөйләмнәрен үстерү, бу юнәлештә эти-әниләр белән эш үзенчәлекләрен ачу буенча киңәшләр бирелде һәм пропаганда эшләре алып барылды. Шул ук февраль аенда халыкара туган телләр көне уңаеннан “Туган тел” атналыгы игълан ителде. Биредә балалар Г.Тукай, А.Алиш әкиятләрен кабат искә төшереп иллюстрацияләр ясадылар. Татар халык табышмаклары һәм мәкальләр көне узды. Ә март аенда исә “Дуслык аланы ” атналыгы уздырдык. Саф һавада рус телендә хәрәкәтле , сүзле хороводлы уеннар уйнадык. “Балаларыбыз иҗаты” исеме астында балалар эше һәм ата-аналарның кул эшләре буенча әкият һәм мультфильм геройларына күргәзмә үткәрдек Рус теле шөгыльләре уртанчылар төркеменнән башлап, һәр төркемдә атнага өч тапкыр үткәрелә һәм С.М.Гаффарованың “Изучаем русский язык”программасына нигезләнеп алып барыла.

Бала инде мәктәпкәчә яшьтә үк, тере һәм тере булмаган табигать,үсемлекләрнең файдасы, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен төгәл үти белергә һәм аңлап эш итәргә тиеш.Тик шулай да бала тиешле дәрәҗәдә табигать турында белем алмый икән,аның белән тиешле дәрәҗәдә кызыксынмаска һәм сакларга кирәклеген, кеше тормышында табигатьнең җитди урынын аңламаска да мөмкин. Шуның өчен дә, бу белемнәрне балаларга танып белү процессын эчтәлеге буенча да, кулланыла торган метод һәм алымнар буенча да кызыклы итеп балаларга җиткерү бурычы тора. Бу бурычларны тормышка ашыру өчен яңа уку елында балалар бакчасының ике төркемендә дә “ ” проекты төзелеп, эшчәнлек оештырылды.

**Балаларның сәламәтлек торышы, сәламәтлекне ныгыту һәм үстерү чаралары.**

Бакчада балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту эше тиешле дәрәҗәдә куелган, шартлар булдырылган. Төп бурычыбызның берсе: мәктәпкәчә тәрбиядә, эшчәнлек төрләрен интеграцияләү аша, өлкәннәр һәм балаларда сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру. Бу иң мөһим мәсьәләгә без түбәндәге чаралар аша якын килеп балаларның авыру очракларын кимәтә алдык: вакытында үләннәр белән чәй эчү, витаминнар белән тәэмин итү, грипп вакытында профилактик чараларның үтәлүе, әти-әниләр белән индивидуаль эшләү, киңәшләр бирү, поликлиника белгечләре белән бәйләнештә булу, көндәлек режимны күзәтеп баруның йогынтысы – болар барысы да уңай нәтиҗә бирде. Барлык тәркемнәрдә дә иртәнге гимнастиканы тиешле гигиеник шартларга туры китереп үткәрү, яз һәм көз айларында өстәмә витаминнар куллану тәэмин ителде.

Балаларның, сәламәтләндерү үзенчәлекләрен аңлату буенча киңәш-консультацияләр уку елы дәвамында уңай нәтиҗәләр бирде.

Физик тәрбия буенча тәрбиячеләр нигездә “Балалар бакчасының гомуми белем бирү программасы”, Н.Е.Веракса, М.А. Васильеваның “От рождения до школы” программасы, өлешчә Л.И.Пензулаеваның “Физическая культура в детском саду” программасы буенча эшлиләр.

Физик сәламәтләндерү эше: иртәнге гимнастика, физик тәрбия шөгыльләре, физкультминутлар, саф һавада булу, хәрәкәтле һәм спорт уеннары, чыныктыру чаралары көн дәвамында һәрдаим алып барылды. Балаларны сәламәт, җитез, чыдам итеп тәрбияләү максатыннан еллык план буенча төркемнәрдә «Күңелле стартлар», «Сәламәт тәндә – сәламәт акыл» кебек спорт иртәләре, кышкы һәм җәйге спорт бәйрәмнәре, “Күңелле стартлар”, “Айболит саулык бирә” исеме астында “Сәламәтлек” көннәре үтте. Әти – әниләр өчен физик тәрбия үсешенә кагылышлы “Дөрес туклануның сере” – туклану культурасы нигезләрен ныгыту максатыннан консультацияләр тәкъдим ителде.

Кечкенәләр төркеменең физкультура почмагында һәм уртанчылар һәм зурлар төркеме өчен группа бүлмәсендә көн дәвамында балаларның мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлеген оештыру, төп хәрәкәтләрне башкару осталыгын ныгыту өчен җитәрлек дәрәҗәдә материаллар тупланган.

Өстенлекле үсеш юнәлешендә максатыбыз:

Әдәби- эстетик үсеш алган шәхес формалаштыру, иҗади эшчәнлек аша балаларның сөйләмен, танып-белү һәм әдәби фикер йөртү мөмкинлеклрен үстерү, яшьтәшләре белән үзара аралашу процессы аша әдәби һәм эстетик кыйммәтләр формалаштыру.

Өстенлекле үсешне тормышка ашыру юнәлешендә түбәндәге бурычларны тормышка ашырдык:

Балаларда сәнгать төрләре буенча элементар күзаллаулар формалашттыру юнәлешендә матур әдәбиятны, фольклорны, музыканы тоярга өйрәттек. Шулай ук ел дәвамында һәм сәнгать әсәрләрен өйрәтү өстендә эшчәнлек алып бардык (сүзле, музыкаль , театраль ).

Иң элек, ук елы башында ук, әти-әниләр белән әдәби китаплар укуга өстенлек бирдек. Әтиләр һәм әниләр көненә багышлап кул эшләреннән күргәзмәләр уздырдык. Балаларның эстетик тойгыларын, иҗади сәләтләрен үстерү юнәлешендә аларның иҗади күзалый өрәтүгә зур игътибар бирелде. Табигать дөньясына, тирәлеккә эстетик караш тәрбияләүгә аерым басым ясадык. Балалар белән әдәби әсәрләрдәге персонажларның кичерешләренә стимул бирә белүләре өстендә эш алып бардык.

Халык иҗаты үрнәгендә балаларның әдәби-эстетик күнекмәләрен һәм әдәби –патриотик тойгыларын үстерү буенча балаларны мәдәни кыйммәтләр, традицияләр үрнәгендә тәрбиялибез.

Әхлакый тәрбия өлкәсендә педагоглар һәм ата-аналарның бердәмлеген булдырдык. Кече туган якка патриотик караш формалаштыру максатыннан ел дәвамында төрле чаралар уздырдык. Патриотик тәрбия буенча проблемаларны хәл итүгә ата-аналарны тарттык.

**Мәктәп белән элемтә**

Гомуми белем бирү структурасын һәм эчтәлеген камилләштерү максатыннан бакча һәм мәктәп хезмәттәшлегенә дә аерым басым ясала. Бакчабыз Байсар урта мәктәбе белән тыгыз элемтәдә тора. Ел башында мәктәп белән элемтә планы булдырылып шул план нигезендә эшчәнлек алып барыла. Бу уку елында да мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячесе Г,Р.Кашапова, мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән, 1 нче сентябрь көнне “Белем иле” бәйрәм иртәсендә катнаштылар. Уку елы дәвамында бакчадан 1 нче класска кергән 6 баланың әлифба дәресен тыңларга тәрбияче Г.Р.Кашапова барды. Бакчада узган ачык ишекләр, ачык шөгыльләр көнендә мәктәпнең башлангыч класс укытучысы һәм укыту буенча директор урыбасары Г.А.Мөфтиева катнашып балалар күрсәткән шөгыльләрне уңай бәяләп китте. Инглиз теле укытучысы Мурзина Эльвира ел дәвамында балаларга инглиз телендә җырлар,шигырьләр өйрәтеп күп төрле бәйгеләрдә җиңү яуланды. Балалар белән белем көненнән башланып киткән бәйләнеш ел дәвамында сузылды. Балаларыбыз мәктәпнең табигать почмагына, музеена, китапханәсендә экскурсияләрдә булдылар.

Бакча педагоглары балалар бакчасында тәрбияләнгән балаларның тормышлары, белем алу өлкәсендә ирешкән уңышлары белән һәрдаим кызыксынып торабыз.

Соңгы өч елдан бакчадан чыккан балалар саны:

| **Уку елы** | **Авылда 6 яшьлек балалар саны** | **Бакчага йөрүче 6 яшьлек балалар саны** | **Бакчадан 1 нче класска чыгу – чы балалар саны** | **Өстәмә белем бирү түгәрәклә ренә йөрүче** |
|---|---|---|---|---|
| 2020-2021 | 7 | 7 | 6 | - |
| 2021-2022 | 4 | 5 | 5 | - |
| 2022-2023 | 5 | 5 | 5 | - |

2023 елда бакчада тәрбияләнеп мәктәпкә керүче 4 бала психик үсешнең дүрт параметры буенча да 2,8- 4 баллдан югары баллларны җыйдылар. Бу үсешнең югары дәрәҗәсендә билгеләнә. Бу балалар үзләренең үсеш дәрәҗәләре буенча үстерешле белем бирү программасын үзләштерергә сәләтле дип табылдылар. Югары балл җыйган балаларның түбәндәге үзенчәлекләренә игътибар итү сорала:

- сөйләмдә аваз кимчелекләре булган балалар белән ел дәвамында тел гимнастикасы, төрле тизәйткечләр, күнегүләр эшләү;
- бәйләнешле сөйләм телен үстерү өчен балаларда монологик, диалогик сөйләм үстерү күнегүләре эшләү;
- 3 балага аваз кимчелекләре буенча логопед ярдәме таләп ителә.

Балаларның бу кимчелекләре буенча аларның әти-әниләре һәм укытучылары белән сөйләшү алып барылды, югарыда язылган тәкъдимнәр өстендә эш алып барыла. Шулай итеп безнең балалар бакчасы чыгарылыш төркеме балаларының белемнәре төпле, инновацион технологияләр, яңа алымнар куллану аларга мәктәптә укырга мөмкинлек бирә. Мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче 5 баланың белем дәрәҗәләре, яшь үзенчәлекләре буенча, үсеш дәрәҗәләре нормаларына туры килә һәм алар үстерешле белем бирү программасын үзләштерергә әзер.

Бакчада җитәкчелек итү системасының төп максаты**:** тәрбия белем бирү процессын, педагогик кадрларның профессиональ компетентлыкларын үстерү процессын, белем һәм тәрбия сыйфатын үстерүне оештыру.

**Тәрбия, белем бирү эшенә контроль һәм җитәкчелек**

Тәрбия, белем бирү эшенә контроль һәм җитәкчелек буенча 2022 - 2023 уку елында бакчада май аенда мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларның белем дәрәҗәләре тикшерелде.

Һәр атна саен мөдир тарафыннан оператив тикшерүләр уздырылып барылды. Контроль эшчәнлекләре еллык план нигезендә төзелгән циклограмма буенча алып барылды. Бакчада торле бәйрәмнәр, күңел ачу иртәләре үткәрелә. Телне яхшырак, тизрәк үзләштерү максатыннан бакчада “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның аваз кимчелекләрен бетерү өстендә эш” проекты буенча эш алып барыла. Татар һәм рус халыкларының, идел буе халыкларының авыз иҗаты, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру, «Сөмбелә», «Нардуган», «Карга боткасы», «Нәүрүз», «Сабантуй», “Каз өмәсе” кебек халык бәйрәмнәре үткәрү матур традициягә әйләнде. Безнең балалар бакчасында педагоглар ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшә , тәрбия һәм белем бирү эшен ике телдә дә уңышлы алып баралар.

**Ата-аналар белән эшчәнлек.**

Балалар бакчасында балаларның һәръяклап үсешен тәэмин итү өчен ата-аналар белән тыгыз эш алып барыла. Педагоглар әти-әниләр белән тыгыз элемтәдә эшлиләр: тәрбия һәм медицина темаларына консультацияләр, эчтәлекле күргәзмәләр, ачык ишекләр көне, әдәп-әхлак, интеллектуаль тәрбиясе темасына әңгәмәләр, бәйрәм кичәләре үткәрәләр, ягъни әти-әниләр белән эшнең төрле формаларын кулланалар. Әти-әниләрнең әдәп–әхлак, интеллектуаль тәрбия темасы өлкәсендә педагогик яктан белемнәрен күтәрүне күздә тотып ел дәвамында бакчада "Сезнең өчен, әти-әниләр!", зурлар төркемендә "Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар", "Тәрбияле бала – ил терәге" коридор өлешендә "Балалар бакчасында ФДББС" исеме астында стендлар булдырылды. Анда бакчаның эш юнәлешләре, әти-әниләр өчен кирәкле һәм файдалы киңәшләр, мәгълүматлар урнаштырылган, алар үзгәртелеп, алмаштырылып торыла. Балаларның төрле табигать күренешләрен чагылдырган, әхлак, теракт, әкият һәм мультфильм геройларын чагылдырган темаларга рәсемнәре һәм әти-әниләр белән берлектә төрле табигать материалларыннан ясалган әйберләр күргәзмәсе еш оештырыла. Әти-әниләр бу күргәзмәләрдә бик теләп катнашалар, үзләренең осталыкларын күрсәтәләр.

Шулай ук, балалар бакчасында әти-әниләр почмагы булдырылган. Анда методик таләпләргә туры китереп көндәлек режим, шөгыльләр челтәре, әти-әниләр өчен кагыйдәләр, башка кирәкле мәгълүматлар урнаштырылган. Барлык төр материаллар сезон таләпләренә туры килә һәм вакытында алыштырыла, үзгәртелә, эчтәлеге баетыла,ике телдә дә алып барыла.

Төрле темаларга консультацияләр, методик тәгъдимнәр, киңәшләр тупланган китап-ширмалар булдырылды. Болар нигезендә әти-әниләр үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар табалар. Бакчада үткәрелә торган барлык бәйрәмнәр, чаралар, шөгыльләр, төрле күргәзмәләр, очрашулар, район күләмендә үткәрелә торган конкурслар әти-әниләр игътибарыннан читтә калмый, алар ярдәме белән яки алар катнашында үтә. Ел дәвамында түбәндәге темаларга уртак иҗат, күргәзмәконкурслар уздырылды: "Без табигать дуслары","Көзге матурлык","Әниемнең җылы куллары", "Кышкы әкият","Кошлар – нәни дуслар", "Мин мультфильм яратам", "Тукай абый иҗаты". Юл хәрәкәте иминлеге буенча , әхлак тәрбиясе буенча , татар халкының иҗатын өйрәнү , патриотик тәрбия буенча әдәби- музыкаль композицияләр, спорт бәйрәме , мастер класслар уздырылды.

Әти-әниләрне дә татар халкының һәм башка милләт вәкилләренең гореф-гадәтләре белән якыннан таныштыру максатыннан төрле күңел ачу чаралары: "Сөмбелә", "Нәүрүз" "Масленица", "Каз өмәсе", "Карга боткасы", "Сабантуй" һ.б. үткәрелә. Барлык төркем тәрбиячеләре дә әти-әниләр белән тыгыз элемтәдә эшлиләр.

Шулай ук бакчаның материал - техник базасын ныгыткан чагында һәм чисталык айлыкларында ата-аналар ярдәмгә килделәр.

2022 - 2023 нче уку елында педагогик коллектив тәрбия һәм өйрәтү эшенең сыйфатын яхшырту өстендә системалы эш алып барды. Коллективның тәрбия-белем бирү буенча эш нәтиҗәләре канәгатьләнерлек дип кабул ителде.

Сөйләм үстерү мөхитын белем бирү программаларына тулысынча яраклаштыруны күз уңында тотарга һәм балаларны мәктәпкә әзерләүдә ата – аналар белән тыгыз элемтәдә торырга.

**Уку елы йомгакларын исәпкә алып, Федераль белем бирү программасы нигезендә - балаларны Россия гражданы буларак тәрбияләү, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гражданлык һәм мәдәни тиңдәшлеге нигезләрен формалаштыру, Россия халкының рухи-әхлакый кыйммәтләренә нигезләнгән мәктәпкәчә белем бирү эчтәлегенең гомуми үзеген булдыру, үз гаиләсенең, зур һәм кече Ватанының тарихын һәм мәдәниятен белүче һәм хөрмәт итүче яшь буынны тәрбияләү, шулай ук балаларны туганнан алып, яшәү урынына**

**карамастан, гомуми белем бирү оешмасына укырга кергәнче бердәм белем бирү тирәлеге булдыру, алдагы уку елында балаларның тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү, сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту, заманча таләпләрне исәпкә алып инновацион алымнар куллану - 2023-2024 уку елына төп бурычлар билгеләнде.**

**I.Еллык планга анализ ясаганнан соң, 2023-2024 уку елында, бакча үсешендә түбәндәге бурычлар билгеләнде:**

1. Федераль дәүләт программасы таләпләрен үтәп, Россия Федерациясенең лаеклы гражданины, үз гаиләсенең, зур һәм кече Ватанының тарихын һәм мәдәниятен белүче һәм хөрмәт итүче яшь буын тәрбияләү, балаларның гражданлык һәм мәдәни тиңдәшлеге нигезләрен формалаштыру;
2. Балаларга туганнан алып, яшәү урынына карамастан, гомуми белем бирү оешмасына укырга кергәнче бердәм белем бирү тирәлеге булдыру , Россия халкының рухи-әхлакый кыйммәтләренә нигезләнгән мәктәпкәчә белем бирү эчтәлегенең гомуми үзәген булдыру;
3. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, Россия халкының рухи-әхлакый кыйммәтләренә нигезләнеп( үз иленең патриоты булган, гадел, җаваплы,мөстәкыйль, җәмгыятьтә үз урынын табып, хезмәт итүче, бар яклап та үсешкә ия булган лаеклы шәхес ) тәрбияләү;

4. Физик, акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерү, әхлакый - сәнгати зәвыклылык тәрбияләү юнәлешендә балаларда милли үзаң формалаштыру. Ике дәүләт теленә карата да хөрмәт тәрбияләү аша дәүләт телләренә өйрәтү сыйфатын күтәрү.

5. “Туган ягым – яшел бишек ” проектына нигезләнеп балаларда кече Ватанын, Туган илен ярату, үзенең яшәгән төбәгенә, табигатькә карата сак караш, матурлыкны күрә белүне үстерү аша балаларда миһербанлылык, кешелеклелек, хөрмәт итә белү сыйфатларын тәрбияләү.

6. Федераль белем бирү таләпләрен тормышка ашыру шартларында педагогларның һөнәри осталыкларын һәм теоретик белемнәрен баету, квалификация дәрәҗәләрен күтәрү өстендә эшне дәвам итү. Хәзерге заман таләпләренә җавап бирерлек бердәм аралашу эшчәнлекләре уздыру.

7. Балалар тәрбияләүдә гаилә һәм балалар бакчасы арасындагы элемтәне камилләштерү. Тәрбиячеләр һәм ата-аналарның балалар каршындагы җаваплылыгын ассызыклап, балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү өчен бердәм белем бирү тирәлеге һәм оптималь шартлар тудыру.

**II.Өстенлекле үсеш юнәлеше: Патриотик тәрбия.**

**Өстенлекле үсеш юнәлешендә максатыбыз:**

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда Туган иле, кече Ватаны турында күзаллаулар булдыру,яшәгән төбәккә, өйгә, гаиләгә, якыннарына, әйләнә-тирә мохитка хөрмәт, сак караш тәрбияләү.
2. Патриотик тәрбия эшчәнлеген, Туган якның, Туган илнең халкы, милли традицияләре, мохиты,тере һәм тере булмаган табигатьне өйрәнүне

экскурсияләр, тәҗрибәләр, хезмәт, күзәтүләр, бердәм эшчәнлек аша тормышка ашыру.
3. Туган илгә , кече Ватанга , гаиләгә, хөрмәт, хезмәт итәргә өйрәнү , табигатькә сак караш, матурлыкны күрә белүне үстерү аша балаларда патриотик, миһербанлылык, кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Балаларны Туган илебез, туган төбәк, төрле милләтләр, көнкүреш, әйләнә-тирә мохит,традицияләр белән таныштыру.
2. Балаларда Туган илне, гаиләне, әйләнә-тирә мохит, табигатьне саклау, өйрәнү аша әхлакый, патриотик хисләр тәрбияләү.
3. Балаларда хезмәткә кызыксыну, хезмәтнең кыйммәтен һәм нәтиҗәсен күрә белүне формалаштыру.
4. Балаларга җәмгыятьтә, табигатьтә үз-үзеңне тоту буенча, беренчел белем һәм күнекмәләр бирү.
5. Балаларны үз иленең лаеклы гражданы итеп тәрбияләү эшендә ата-аналар, җәмәгать оешмалары, тәрбиячеләр белән бердәм эшчәнлек оештыру.

**III. Бакчада эшчәнлекнең вариатив формасы - консультатив пункт.**

**«Без булачак укучы» төркеме.**

**Максат:** эти-әниләр белән берлектә зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балаларын мәктәпкә әзерләү.

**Бурычлар:**

Мәктәпкә баргач балаларда бертигез башлангыч мөмкинлекләр булдыру өчен, 5-6 яшьлек балалрга һәм аларның ата-аналарына төрле яклап ярдәм күрсәтү.

**Байсар балалар бакчасының еллык бурычларны тормышка ашыру планы.**

**КАДРЛАР БЕЛӘН ЭШ.**

**1.Педагогларның һөнәри квалификациясен күтәрү һәм социаль активлыгын үстерү.**

**1.1. Педагогларның үз белемнәрен күтәрү курслары, аттестацияләр.**

| № | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **Курслар.** | 2022 ел<br>2022 ел<br>2023 ел | Хаертдинова Г.М.<br>Кашапова Г.Р<br>Садриева Р.Г | |
| 2 | **Аттестация** | 2022 ел<br>2019 ел<br>2020 ел | Садриева Р.Г<br>Кашапова Г.Р<br>Хаертдинова Г.М | |

### 1.2. Тәрбиячеләрнең методик темалары.

| №п | Тәрбияченең исем, фамил. | Темасы | Алынган вакыты | Тәмамланган вакыты. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Хаертдинова Г.М. | Инновацион проектлар куллану һәм заманча таләпләрне үтәү аша педагогларның һәм балаларның иҗади сәләтләрен ачу. | 2019 ел | 2024 ел |
| 2. | Кашапова Г.Р. | Балаларда аваз кимчелекләрен бетерү өстендә эш. | 2021 ел | 2026 ел |
| 3. | Садриева Р.Г | Уеннар аша балаларның сөйләм телләрен үстерү. | 2020ел | 2025 ел |

### Район методик берләшмәсе утырышларында катнашу:

Мөдирләр кинэшмәсе – Хәертдинова Г.М. ,тәрбиячеләрнең район методик берләшмәсенә – Кашапова Г.Р., тәрбияче;рус теле буенча район методик киңәшмәсенә Кашапова Г.Р - беренче квалификацион категорияле тәрбияче; ясле район методик берләшмәсе – Садриева Р.Г беренче квалификацион категорияле тәрбияче.

### 1.3.Мөдир яны киңәшмәсе.

| №п\п | Чаралар | Җавплы кеше | Вакыты. | Үтәү формасы. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Киңәшмә | Хәертдинова Г.М. | Һәр атнаның дүшәмбесе | телдән |

## II. Педагогик оештыру эшчәнлеге.

| № п\п | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы. |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **Семинар - практикум**<br>Тема: «Балаларның сәламәтлеген саклау,вируслы чирләргә каршы торучанлыкны ныгыту буенча профилактик чаралар».<br>1.Теоретик материалны тәкъдим итү.<br>2.Тәрбиячеләргә бирем:<br>Балалларның яшь үзенчәлекләренә карап, һәр төркемдә дә сәламәтлекне саклау, дөрес туклану, гигиена таләпләрен үтәү, чыныктыру чаралары буенча буенча күнегүләр Һәм уеннар системасын, материаль базаны булдыру.<br>3. «Тәҗрибә белән уртаклашам» эш буенча тәрбиячеләр чыгышы.<br>4. Тәрбиячеләр өчен өйгә биремне карау, анализ ясау.<br>5. Балалар өчен уен күнегүләре «Уен- сәяхәт».<br>6.Ата-аналар белән эш:<br><br>- Балалар табибы белән очрашу,консультацияләр<br>- тема буенча тәкдимнәр.<br>7. Семинарга йомгак ясау. | 01.09.2023<br>30.11.2024 | Г.М.Хаертдинова | План, справка, конспектлар |
| 2 | **Ата-аналар өчен семинар**<br>**Тема:** «Баланың мәктәпкә әзерлеге»<br>1. Баланың мәктәпкә авыр яраклашу сәбәпләре.<br>2. Әзерлекне билгеләү методикалары, мониторнг.<br>3.«Мәктәпкә кергәндә бала ниләр белергә тиеш?»<br>4. «Мәктәпкә керүче баланың сөйләме, психологик яктан әзерлеге».<br><br>5. Тәкъдимнәр | 26.04.2024 | Хәертдинова Г.М.<br>Кашапова Г.Р. | План, справка, конспектлар |

## II.1. Консультацияләр.

| № п\п | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы. |
|---|---|---|---|---|
| 1. | “ Балалар бакчасында патриотик тәрбия” | Ноябрь | Хәертдинова Г.М. | Әңгәмә, |
| 2. | «Педагогик эшчәнлек формасы буларак бала белән индивидуаль эшчәнлек» | Декабрь | | |
| 3. | Баланың туган телдә сойләмен үстерүдә УМК, ИКТ, дидактик, үстерешле уеннарның тәэсире. | Март | Кашапова Г.Р. | Язмача информация |
| 4. | Балаларның сөйләмен үстерүдә кул моторикасының роле | Апрель | Садриева Р.Г. | |

## Техник эшчеләр белән.

| №п\п | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы. |
|---|---|---|---|---|
| 1.<br>2.<br>3. | Эшчеләрне яңа уку елына эш сәгатьләре графигы, уборка графигы, хезмәт вазыйфалары белән таныштыру.<br>Савыт-сабаларны юу, җилләтү һәм постельләрне алыштыру кагыйдәләре.<br>Балаларның иминлеген тәэмин итү максатыннан терракткa каршы эшчәнлек. | Сентябрь<br>Сентябрь<br>Декабрь | Хәертдинова Г.М. | Әңгәмә,<br>Язмача информация |

**П е д а г о г л а р   б е л ә н   эш**

| №п\п | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Зурлар төркемендә сөйләм һәм танып белү үсеше буенча "Туган илем – яшел бишек" темасына эшчәнлек. "Эко дети " конкурсына әзерлек. | Ноябрь | Кашапова Г.Р. | Конспект |
| 2. | "Туган җирем Татарстан" темасына дидактик уеннар, күрсәтмә материал. | Декабрь | | |
| 3. | Беренче кечкенәләр төркемендә: "Туган өем" темасына эшчәнлек. | | Садриева Р.Г. | Конспект |
| 4. | Мәктәпкә әзерлек төркемендә эстетик – сәнгать үсеше:<br>- Квест уен формасында; | Январь | Кашапова Г.Р. | Конспект |
| 5 | Зурлар төркемендә «Сәнгать дөньясы белән танышу» белем бирү эшчәнлеге<br>Татар халык сүзле- җырлы уеннар. | Апрель | Садриева Р.Г. | Конспект |

## II.5. Алдынгы эш тәҗрибәсен тарату.

| № | Тема | Өйрәнү | Гомумиләштерү | Тарату |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән музыкаль-театраль эшчәнлек. | 2023-2026 | 2026 | Методик ярдәмлек |
| 2. | «Сөйләмдә аваз кимчелеге» буенча эш материаллары | 2023-2026 | 2026 | Методик ярдәмлек |
| 3. | " Туган ягым- яшел бишек" проект | 2023-2026 | 2026 | Методик ярдәмлек |

## III.Тәрбия, белем бирү эшенә контроль һәм җитәкчелек.

### Тематик тикшерү

| № | Тикшерү төре | Вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
